**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Кече Салтык авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**«30» декабрь 2019ел** **№ 142**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советының «Җирле салымнар һәм җыемнар буенча пенялар, штрафлар недоимкалары һәм бурычларын түләтү һәм исәптән чыгаруны өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен раслау турында» 2019 ел, 17 октябрь, 133 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты нигезендә № 54-ТРЗ от 19.07.2017 ел, № 54-ТРЗ «Региональ салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану өчен өстәмә нигезләр билгеләү турында», 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы һәм, җирле салымнар һәм җыемнар буенча бурычларны түләттерүгә, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы **КАРАРЫ:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советының “Җирле салымнар һәм җыемнар буенча пенялар, штрафлар недоимкалары һәм бурычларын түләтү һәм исәптән чыгаруны өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен раслау турында”гы 2019 ел, 17 октябрендәге, 133 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Карарның 1 пунктындагы 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) 2007 елның 2 октябрендәге 229 - ФЗ номерлы «Башкарма производство турында" Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктларында каралган нигезләр буенча башкарма җитештерүне тәмамлау турында суд приставы-башкаручы тарафыннан карар чыгарылуга бәйле рәвештә башкарма документлар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны мәҗбүри түләттерү мөмкинлеге булмау;»;

Карарның 1 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) үлгәннәрнең яки вафат булучыларның пенялары һәм штрафлары буенча бурычлары, варисларның мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас алмаган очракта, мирас ачылганнан соң өч ел дәвамында Россия Федерациясе Граждан-процессуаль законнары белән билгеләнгән тәртиптә булу.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән нигезләр булганда, җирле салымнар буенча недоимканы түләттерүгә өметсез дип тану, бу салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычлар булуын раслаучы документлар булып торалар:

1) салым гамәлдән чыгарылу турындагы норматив хокукый акт турында белешмәләр (исеме, номеры, датасы);

2) тулэтеп булмаслык недоимка суммалары, пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычлар турында салым органы белешмәсе;

3) 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы «Башкарма производство турында" Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктларында каралган нигезләр буенча башкарма документны түләтүчегә кире кайтарганда суд пристав-башкаручысы карарының күчермәләре»;

4) физик затларның Граждан хәле актларын теркәүне гамәлгә ашыручы орган тарафыннан Россия Федерациясе Салым кодексының 85 статьясындагы 3 пункты нигезендә салым органына кергән үлем фактын теркәү турында белешмәләр»;

5) мираска хокук турында таныклык бирү турында белешмәләрнең булмавы турында салым органы белешмәсе.».

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кече Салтык авылы, Бакый Урманчы урамы, 9 нчы йорт;

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кече Мәрәтхуҗа авылы, Вахитов урамы, 9 нчы йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Кече Салтык авыл җирлеге Башлыгы,**
**Татарстан Республикасы**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Кече Салтык авыл җирлеге Советы рәисе** **А.Г. Җиһаншин**